ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 12 сентябре** **Чистай шәһәре** **№ 593**

Муниципаль дәрәҗәдә, хисап чорында декомпозицияләнгән «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы эшчәнлеге регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы указлары нигезендә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль дәрәҗәдә, хисап чорында декомпозицияләнгән «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы эшчәнлегенең кушымта итеп бирелә торган регламентын расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында https://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы О.В. Купцовага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

2022 елның 12 сентябрендәге 593 номерлы карарына кушымта

**Муниципаль дәрәҗәдә, хисап чорында декомпозицияләнгән «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентны көйләү предметы.

Муниципаль дәрәҗәдә, хисап чорында декомпозицияләнгән «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы эшчәнлегенең әлеге регламенты, Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге һәм шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указлары, «Татарстан Республикасы Электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы «Контроль» модуле эшчәнлеге тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнгән һәм муниципаль дәрәҗәдә, хисап чорында декомпозицияләнгән «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны җыю һәм мониторинглау (алга таба - декомпозицияләнгән күрсәткеч) тәртибен билгели:

мәктәпкәчә белем бирү буенча белем алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны;

дәүләт яки муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны.

Чистай муниципаль районында декомпозицияләнгән күрсәткечләрне җыю һәм мониторинглау өчен җаваплылык үзәге - Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе (алга таба - мәгариф идарәсе).

1.2. Белешмә мәгълүмат.

Әлеге регламент максатларында, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикаларын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17

июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары белән кертелгән муниципаль дәрәҗәдә, хисап чорында декомпозицияләнгән «Белем дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге» күрсәткечен хисаплау методикасында билгеләнгән терминнар кулланыла.

## 2. Хисаплау стандарты, җыю тәртибе, һәм мәгълүмат бирү

Декомпозицияләнгән күрсәткечне исәпләү өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

мәктәпкәчә белем бирү буенча белем алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны;

дәүләт яки муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны.

Мәгариф идарәсенең җаваплы хезмәткәре мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалардан югарыда күрсәтелгән хисап чорында әлеге мәгълүматларны җыя.

Муниципаль район буенча җыелма мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында рәсми хат белән бирелә.

## 3. Мәгълүматның составы, вакыты һәм формасы

3.1. Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалар тарафыннан әлеге мәгълүматларны бирү формасы таблицада күрсәтелгән.

Таблица

Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны

| т/б | Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм аларны җибәрү буенча хезмәт күрсәтүче оешманың исеме | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Мәгълүмат бирү вакыты хисап артыннан барган айның 1 көненә кадәр | Дәүләт яки муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны | Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |